*Нуриев Г. С. (РИИ, Казань)*

# РИТОРИКА ҺӘМ ХӨТБӘ-ВӘГАЗЬЧЕЛЕК БАГЛАНЫШЛАРЫ (СООТНОШЕНИЕ РИТОРИКИ И ХУТБ-ПРОПОВЕДЕЙ)

**Аннотация:** Статья «Соотношение риторики и хутб-проповедей» посвящена выявлению соотношения риторической модели речи и мусульманского проповедничества (религиозной риторики). В работе представлены основные взгляды риторики на существенные особенности хутб-проповедей.

**Ключевые слова:** риторика, исламское вероучение, дискурс, иллокуция, хутба, проповедь, типичная речевая ситуация.

**The ratio of rhetoric and sermons preached on Fridays at all**

**Abstract:** The article is devoted to identification of the ratio of rhetorical models and muslim preaching. The author presents the main views on the essential features of sermons preached on Fridays at all.

**Key words:** rhetoric, the Islamic creed, a discourse, allocution, Khutbah, a sermon, a typical speech situation.

Уку-укыту эшчәнлеге белән бәйле замандашларыбыз телендә төрле эчтәлеккә яраклаштырылган риторика сүзе соңгы вакытта бигрәк тә еш кабатлана башлады. Тормышыбызның башка өлкәләрендә дә риторика, бер үк мәгънәдә, бер үк эчтәлектә аңлашылмаса да, киң кулланышта. Бүген дә ул риторик максат

(идеал), «риторик өлге (модель)» [Михальская 1996: 379; Варзонин 2002: 26] күзлегеннән караганда төрле яссылыкта яши, кайвакыт, риторика дип тә аталмый. Шул сәбәпле хәзерге җәмгыятьтә аралашу мәсьәләләрен тикшергән башка фәннәр чолганышында, риторикага, фән буларак үзенең йөзен саклап калырга туры килә.

Сүзебезне риторика белән бик якын багланышта булган – хөтбә-вәгазьчелек – дини риторика (башка телләрдәге гомилетика төшенчәсенә тәңгәл килә) турында дәвам итик. Риторика белән хөтбә вәгазьчелекнең үзара бәйләнеш мәсьәләләрен тикшерү берничә сәбәп белән аңлатыла.

Хәзерге риторика, аралашуга бәйле башка фәннәр рәтендә, күп кенә табигый һәм гуманитар фәннәр белән хезмәттәшлектә. Шулай да, риторика һәм дин белеме (теология) багланышлары турында фикерләр аз яңгырый. Ислам мәдәниятендә хөтбәчелек, вәгазь сөйләү алым-ысулларында нәтиҗәле аралашу асылына кагылышлы күпме кыйммәтле мәгълүмат һәм тәҗрибә тупланган [Җүрҗани; Абызгилдин 1918]. Риторика буенча дәреслек-уку әсбапларында дини-рухани сөйләм үзенчәлекләре турында бүлек-бүлекчәләр урын алса да, алар риториканың гомумтеоретик кысаларыннан читләтелгән рәвештә язылган. Дөньяви басмаларда, дини күзлектән үткәргәндә, төгәлсезлекләр дә очрап тора. Әлеге җитешсезлекләр бүгенге фән юнәлешендә дини тәгълимат һәм дини тәҗрибәнең тиешенчә өйрәнелеп бетмәвеннән, аларның гуманитар белемнәрнең җитди чыганагы буларак кабул ителмәвеннән килә.

Шул ук вакытта хәзерге сәяси шартлар ислам дине белеменең тәгълимати һәм кешеләрнең үзара аңлашу барышына (когнитив яссылык) иҗтимагый әһәмияткә ия максатчан йогынты ясарлык гамәли өлешләренә уңай мөнәсәбәткә юл ачалар. Җәмгыятебездә мөселман өммәте көннән-көн ишәя, массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан дини тормышның үрнәк яклары да күбрәк яктыртыла («Дин вә әдәп» журналы, «Дин вә мәгыйшәт», «Иман» газетлары).

Ислам диненең көчәюе, атеистик юнәлештәге гадәти гуманитар белемнәргә ия булган кешеләрдән үзгә фикер йөртүче, башка рухи кыйммәтләр белән шөгыль-фигыль кылучы, аралашуда милли гореф-гадәтне торгызучылар даирәсенең киңәюенә алып килде. Әлеге күренеш хәзерге җәмгыятьтә мәгълүмати-аралашу

даирәсенең яңа эчтәлеген һәм аның нинди нәтиҗәләргә китерәчәген тәфсилле өйрәнү ихтыяҗын алга куйды.

Риторика кысаларында хөтбә-вәгазьчелеккә игътибар артуның икенче бер сәбәбе: әлеге аралашу рәвешенең риторика тарихында һәм, гомумән, иҗтимагый тормыштагы әһәмиятенә бәйле. Һичсүзсез, хөтбә-вәгазьчелек, үгет-нәсыйхәт кылу мөселман дөньясында риториканың билгеле бер чордагы үсешенә дә зур йогынты ясаган. Хөтбәчелекнең асылын тәшкил иткән вәгазь сөйләү ислам тәгълиматы киң таралганчы ук билгеле булган, шулай ук, дөньяда ислам дине көчәюдә дә бик әһәмиятле урын биләгән.

Искәртеп үтик, «Тел-сөйләм һәм дин» темасы соңгы елларда татар тел гыйлемендә дә ныклап өйрәнелә башлады. Лингвистик тикшерүләргә «Коръәни-Кәрим тексты, пәйгамбәрләр тарихы, рухани әдәбият ядкярләре, догалар җәлеп ителә башлады. Күп очракларда дини текстлар белән мәгънәви, грамматик, стилистик һәм башка лингвистик тикшеренүләр үткәрелә, дини текстларны тәрҗемә итү мәсьәләләре карала, дини лексиканың мәдәни һәм көндәлек тормышта кулланылышы өйрәнелә, вәгазь җыентыклары дөнья күрә («Йөз дә бер вәгазь», «Вәгазьләр, әдәп-әхлак китабы», «Табын» һ. б.).

Вәгазь үзе сәяси һәм хөкем чыгышлары кебек үк ораторлык сәнгате үрнәгеме, я булмаса, аның асылы классик риторика кысаларына бөтенләй туры килмиме? Хөтбә (гар. хотбә – речь, нотык) – җомга һәм дини бәйрәмнәрдә укыла торган намазларда, дин тотучыларга мөрәҗәгать итеп, имам тарафыннан сөйләнә торган вәгазь. Урта гасырларда ул, нигездә, Алладан хәлифә һәм патшаларга, ханнарга сәламәтлек сорап укыла торган дога булган. Гаскәргә җиңү, халыкны корылык, ачлык кебек афәтләрдән имин итүне сорап та хөтбә укыганнар [ИБС 1993: 152]. «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә хөтбә (хотбә) сүзенең ике мәгънәсе теркәлгән: 1) Речь, нотык, сөйләнгән сүз. 2) Вәгазь [ГТРАС, II 1993:665].

Вакытлар узу белән, хөтбәләрнең максат-ниятләре дә, эчтәлекләре дә, сөйләү тәртипләре һәм рәвешләре дә үзгәрә, аларның яңадан-яңа үзенчәлекле төрләре барлыкка килә. Шулардан чыгып, хөтбәләрне, нигездә, дүрт зур төркемгә берләштерергә мөмкин: 1. Дини хөтбәләр; 2. Сәяси хөтбәләр. 3. Мәхкәмә хөтбәләре. 4. Тормышкөнкүрешкә караган хөтбәләр. (Җ. Абызгилдин соңгы төркемне «мәдех хөтбәләре»,

«тәбрик хөтбәләре» дип аерып биргән).

Мәчет-мәдрәсәләрдә, җомга һәм гает намазларында, дини бәйрәмнәрдә һәм мәрсияләрдә укыла торган дини хөтбәләрнең төп максаты – тыңлаучыларда илаһи хис уяту, халыкка дини тәрбия бирү, аларны рухландыру [Абызгилдин 2013:358].

Гадәттә, хөтбә 5 өлештән тора: 1) Аллаһны мактау; 2) Пәйгамбәр һәм хәлифәләр рухына дога кылу; 3) Аллаһының берлеген раслау; 4) Вәгазь уку; 5) Мөселманнар исәнлегенә дога кылу [ИБС 1993:152].

Хөтбәнең вәгазьгә караганда киңрәк төшенчә булуы күренә. Әмма шунысы ачык аңлашыла: хөтбәдән башка җомга һәм гает намазлары, ә вәгазьдән гайре хөтбә була алмый. Шуңа күрә Габделхак хәзрәт Саматов билгеләп үткәнчә: «Хөтбә шул ук вәгазь инде. Шуңа күрә әйтеләсе сүзләр, вәгазьләр шул хөтбәгә керергә тиеш <...>. Хөтбә ул – кешеләрнең күңелләренә тәэсир итә торган һәм иманы артуга сәбәп була торган бер вәгазь» [Саматов 2005:303].

Гарәп теленнән алынган вәгаз сүзе «Вәгазь, үгетләп, димләп, өндәп сөйләнгән сүз» дип шәрехләнә [ГТРАС, I 1993:54]. «Аңлатмалы сүзлек»тә ул ике мәгънәдә бирелә: «1. Үгет, нәсыйхәт, яхшылыкка өндәү. 2. Мәчеттә гыйбрәтләр китереп, дини нәсихәт бирү төсендәге чыгыш» [ТТАС, I 1977: 245].

Дөрес, вәгазь сөйләү чыгыш ясаудан үзгә, бөтенләй башка халәттә уза, оештыру рәвешләре дә төрле. Искәртеп үтик, бер-ике аерымлыкка карап тел-сөйләм һәм үзара аралашу мәсьәләләрендә ашыгыч нәтиҗәләр ясау килешми. Бүгенге дөньяны танып белү фәненә нигезләнеп, лингвистик тикшеренү берәмлекләре буларак сөйләм һәм дискурс (вакыйгалар узышына бәйле рәвештә текстны эзлекле, ритмик, мәгънәви яктан оештыру; хисси бәяләү, тыңлаучыга йогынты ясау (иллокуция); төп фикерне ныгыту чараларын да исәпләп, куелган максатка ирешү) белән беррәттән иҗтимагый-мәдәни, күңелфигыль мөмкинлекләрен дә кертеп, кеше үзе дә өйрәнелә. Ә шәхесне яки төрле төркемнәргә берләшкән кешеләрне теленә (сөйләменә), милләтенә һәм диненә карап сыйфатлыйлар [Мечковская 1998: 9]. Кешенең тоткан динен аның асыл сыйфаты дип таныган хәлдә, аралашу даирәсен дини фикерләренең тормышта кулланылуы дип күзаллаганда, хөтбә-вәгазьчелекне лингвистика, риторика яссылыгында җентекләп өйрәнү бик мөһим.

Хөтбәчелекнең вәгазь барышында тормышка ашырыла торган (ашырылырга тиеш) төп кагыйдәләре кабатлан-

мас риторик гамәл барлыкка китерә. Җәгъфәр Мөбарәк хөтбә сөйләүнең әһәмияте турында: «мөселманнарның йөрәгенә гайрәт кертә, аларны шатландыра, елата, үкендерә, дәртләндерә, яшен-картын, баен-фәкыйрен берләштерә. Аллаһы Тәгаләгә инанырга, бер максатка юнәлергә өнди. Аларга бертөрле хис, бертөрле юнәлеш бирә», –дип искәртә [Мөбарәк 1998: 11].

Хөтбә-вәгазь сөйләүнең дә үз хасиятләре, үз тәртибе бар. Күренекле имам-хатыйб һәм галим Җ. Абызгилдин хөтбә-вәгазьчелеккә булган төп шартларны һәм таләпләрне билгеләп, риторик максатның кайбер элементларын да кертеп, үзенчәлекле риторик өлге тәкъдим итә:

1. Хөтбәнең төп мөндәриҗәсе (эчтәлеге) тәгаенләнгән, ягъни алдан хәзерләнеп, кулдан язылган кыскача эчтәлеге булырга тиеш.

2. Хөтбәне изах вә шәрех итеп (төшендереп, ачыклап), мөмкин кадәр гомум халыкның ихтыяҗына карап сөйләргә кирәк.

3. Хөтбәдә гомум халыкка нык тәэсир итәрлек, тыңлаучыларның йөрәк вә рухани хисләрен уятырлык булган бер кыйсем, ягъни бер өлеш булырга тиеш.

4. Хөтбәне тәмамлар алдыннан, тавышны аз гына түбәнәйтеп, Аллаһы Тәгаләгә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәмед вә сәнә укып дога кылыныр.

5. Хөтбәләр урынына карап, бик үткен гыйбарәләр белән булып, бәгъзе вакытта кызганычлык хисе китерә торган итеп, ә бәгъзе вакытта шагыйранә тасвирлар китереп, дустанә кылып сөйләргә тиеш, ягъни менә шул урыннарны белеп, алардан дөрес файдалана белү һәрбер имам-хатыйбка лаземдер.

6. Хөтбәнең ана телендә сөйләнә торган өлешен һәр милләт вәкиле кызыгырлык итеп, сөйләм осталыгын гали ноктасына җиткереп сөйләү лаземдер.

7. Хөтбәнең үзен башламактан әүвәл, ул хөтбәнең максаты бәян ителгән бер кыйсем булырга тиеш. Бу кыйсемне ишетү белән һәркемнең дәрте вә Исламга карата мәхәббәт хисе кузгалып, сөйләнәчәк хөтбәгә игътибарлары артыр. Табигый ки, һәрбер хөтбә Исламның бик әһәмиятле бер мәсьәләсен ачыкларга тиеш [Абызгилдин 2013: 359].

Күзәтелгәнчә, хөтбә-вәгазьчелекне ислам тәгълиматы һәм гомум риторика кушылмасы дип, вәгазь кысаларында узган аерым бер төре дип раслыйбыз. Риторикадан аермалы буларак хөтбә-вәгазьчелекнең үзенчәлеге – Аллаһ юлында нәтиҗәле

аралашу ысулларын эзләү, тыңлаучыларга Аллаһның ризалыгына, мәрхәмәтенә, рәхмәтенә өмет-ышаныч уята алырлык сөйләм чараларын куллана белү. Риторик максат һәм риторик өлгегә җавап бирә торган бу дини гамәлнең аерылып торган әһәмиятле билгесе булып, аның ислам тәгълиматы һәм дини фикерләүгә нигезләнгән, аермачык белдерелгән яки фаразланган максатның үтәлүенә юнәлтелгән төзелеше (типик хәлләрдә текст эчтәлеген дөрес аңлату максатыннан сөйләм оештыру чараларын билгеле бер рәвештә урнаштыру (сценарий төзү) тора. Икенче бер төп күрсәткече – хөтбәченең (вәгазь сөйләүченең) үзара аралашу барышына максатчан йогынты ясарлык аралашу даирәсе оештыруыннан гыйбарәт.

Нәтиҗә ясап, вәгазьнең асыл сыйфатлары турында нәтиҗә ясап, шуны әйтә алабыз:

– филология һәм иҗтимагый аралашуны өйрәнә торган фәннәр чолганышында хөтбә-вәгазьчелек мөселманча фикерләү һәм дини әдәпне аралашуның беренче максаты итеп куя;

– вәгазьне риторик кысаларда оештыручы буларак, вәгазьче шәхесенең асыл сыйфаты – ислам тәгълиматына инануы. Аның сөйләменең нияти даирәсе (танып белү, әдәп, зәвык концепциясе) дә һәм аралашу тәртибе дә ислам дине кануннарына нигезләнә;

– дин эшлеклесе һәм мәхәлләдәшләренең аралашуы тел-сөйләм (лингвистик) һәм сөйләмнән тыш – экстралингвистик (гәүдә торышы, ым-ишарә, тавыш тоны, көче, тизлеге, тембры үзгәрү һ. б.) чаралар җыелмасы гына түгел. Ул сөйләмнең билгеләнеп куелган (институциональ) һәм тел-сөйләм чараларыннан үзгә төзелешеннән аерылып торган гадәти аралашуы гына да түгел. Тормышта вәгазь, гыйбадәт кылу һәм дини йола үтәү кысаларыннан чыгып, сөйләмнән тыш мәгънәле чаралар белән дә тулыландырыла. Вәгазь дини эчтәлектә генә дә булмаска мөмкин: мәсәлән, гомумкешелек кыйммәтләре, башка дин тотучыларга карата түземлек; көндәлек тәртип, эшчәнлек эчтәлегенә төшендерүдә дә үгет-нәсыйхәт кулланыла;

– аралашу барышының вәгазь дәрәҗәсенә җитүен без вәгазьченең үзгә бер әһәмияткә ия йогынты ясый алуында күрәбез. Вәгазьченең үзгә аралашу ниятенә ирешүдә тыңлаучыларына максатчан йогынты ясарлык, әлеге йогынтының нәтиҗәсен ныгытып куярлык психологик халәт оештыра алуын без төп күрсәткеч итеп саныйбыз;

– вәгазьнең нияти эчтәлеге ислам тәгълиматында гөнаһ вә савап саналган төшенчә-

гамәлләрне тәгаенли торган типик сөйләм ситуациясендә оештырыла.

– вәгазьнең, дини аралашу чарасы буларак, риторик идеал югарылыгында үзенчәлекләре аңлатылып бетмәгән, шул сәбәпле телче галимнәргә һәм дин әһелләренә иҗтиһад кылу мөмкинлеге әле ябылмаган.

Литература:


1.Абызгилдин Җ. Хитабәт ысуллары. – Уфа: «Тормыш», – 57 б. Мөбарәк Җ. Исламда мөһим мәсьәләләр. / Абызгилдин Җ. Хитабәт ысуллары. – Казан: Раннур, 2013. – 688 б. / Б. 350 – 370

2.Варзонин Ю.Н. Теоретические основы риторики. – Тверь, 1998: –120с.

3.ГТРАС – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – 2 томда. – I том. – Казан: Иман, 1993. – 853 б. 1.ГТРАС – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – 2 томда. – II том. – Казан: Иман, 1993. – 853 б. 1.ИБС – Ислам. Белешмә-сүзлек (төз. З. Шәфигый. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 191 б.

2.Мечковская Н.Б. Язык и религия: Пособие для студентов гуманитарных вузов. – М.: Агентство «ФАИР», 1998. – 352 с.

3.Михальская А.К. Основы риторики: Мысль и слово: Учеб. пособие для учащихся 10-11 кл. – М.: Просвещение, 1996. – 416 с.

4.Мөбарәк Җ. Дин әһелләре белергә тиешле догалар. – Казан: «Иман» нәшр., 1998. – 21 б.

5.Мөбарәк Җ. Исламда мөһим мәсьәләләр. / Абызгилдин Җ. Хитабәт ысуллары. – Казан: Раннур, 2013. – 688 б. / Б. 350–370

6.Саматов Г. Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтвә җавап-савап киңәшләр. – Казан: «Идел-пресс», – 352 б.

7.ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – 3 томда. – I том. – Казан: Татар кит. нәшр.,1977. – 476 б.

8.الجرجاني عبد القاهر. أسرار البلاغة. - بيروت: المكتبة العصرية, 2001. - 316 ص
9.الجرجاني عبد القاهر. دلائل الإعجاز. - بيروت: دار الكتاب العربي, 2005. - 415 ص